ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

2023 елның 23 ноябре №6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында гражданнар җыены **Карар кабул итте**:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлеге территориясендә Бакырчы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр , мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. җирлек чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру;

2. урам утларын ремонтлау һәм карап тоту, кирәк-яраклар һәм компонентлар сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлау;

3. смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру.

3. Әлеге карарны Акъегет авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырырга: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Акъегет авылы, Үзәк урамы, 4 йорт, Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) " Интернет» челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында ( http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Хәйрул А. В. Хәйруллина